СОВЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станции
Высокая Гора, Высокогорский район,
Республика Татарстан, 422700

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

Кооперативная ур, 5. Биектау т/ю
станциясе поселогы, Биектау районы,
Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

---

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

30 июль, 2026 ел № 85

**Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Глухово авылын бетерү турында**

«Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2025 елның 20 мартындагы 33-ФЗ номерлы Федераль закон, «Татарстан Республикасының административ-территориаль төзелеше турында» 2005 елның 07 декабрендәге 116-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 26 статьясындагы 7 пункты, «Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» 2005 елның 31 гыйнварындагы 20-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Биектау муниципаль районы Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Биектау районы Глухово авылын бетерергә.
2. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Глухово авылын бетерү һәм «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең һәм аның составындагы муниципаль берәмлекләрнең территорияләре чикләрен билгеләү һәм аларның статусы турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» Татарстан Республикасы законы проектын закон чыгару инициативасы тәртибендә Татарстан Республикасы Дәүләт Советына кертергә.
3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советында күрсәтелгән Татарстан Республикасы законы проектын караганда Биектау муниципаль районы Советы вәкиле итеп Шакиров Әнәс Шәүкәт улын - Биектау муниципаль районы Башлыгы урынбасарын билгеләргә.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә
5. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Биектау муниципаль районы Башлыгы урынбасары Ә.Ш. Шакировка йөкләргә.

Совет рәисе,
муниципаль район Башлыгы Р.Ф.Хисамутдинов